# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ

КАРАР №7

Урыссу штб __14.11.2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 25.04.2024 елның 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 3 өлеше, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 20.03.2025 № 33-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»гы 30.10.2014 ел, № 82-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 25.04.2024 № 5 карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент түбәндәгеләргә карата:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;

2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,2 процент;

3) 0,3 процент түбәндәгеләргә карата:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм кучемсез комплекслар;

4) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

5) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата 1,2 процент;

6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент.».

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"гы 2024 елның 25 апрелендәге 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 13.09.2024 ел, № 35 карарын һәм "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 2024 елның 12 ноябрендәге 38 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының
"шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе"
муниципаль берәмлеге Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин